Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы

**КАРАР** № 22

Зур Мәшләк авылы 2024 елның 15 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Башлыгы урынбасарын сайлау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 маддәсе, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Зур Мәшләк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 33 һәм 45 нче маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Башлыгы урынбасары итеп Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең бер мандатлы 6 нче округы депутаты Гарипов Илфат Нәгыйм улын сайларга.

2. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Балык Бистәсе районы Зур Мәшләк авылы, Мәктәп урамы, 13А йорты; Югары Мәшләк авылы, Нариманов урамы, 24А йорты; Бикчурай авылы, М.Горький урамы, 50А йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Шәмсев М.М. Шәмсевәлиев